


























**“Шәрык кичәсе”**

сценарий авторы

Гөлназ Дениз

продюсеры

Алима Салахутдинова



# Пьесадагы шәхесләр турында мәглүмат

| | | |
|---|---|---|
| **Драматург һәм артист – Кәрим Тинчурин (1887-1938)** (тулы ак йөзле, зур гына соры күзле, нык, базык гәүдәле җитез кеше) |  | **Кәрим Тинчурин** – татар драматургиясенең классигы, күренекле артист һәм режиссер, татар профессиональ театры һәм драматургиясенә нигез салучыларның берсе.Репрессия корбаны. 1938 дә атып үтерелә. 1955 тә аклана. |
| **Гөләндәм туташ Солтанова** (кара төстә тар озын күлмәк, биек үкчәле туфли, башында энҗеле калфак) |  | **Гөләндәм туташ Солтанова -** Татар классигы Әмирхан Еникинең “Гөләндәм туташ хатирәсе” исемле танылган әсәренең баш каһарманы, музыка һәм китаплар яратучы кыз. |
| **Артист – Өммегөлсем Болгарская (1891-1968)** (юка-озын гәүдәле, ак чырайлы, гел елмаеп кына сөйләшә) Өстендә озык күлмәк, күлмәк өстеннән матур шәл ябынган, калфак кигән. |   | **Өммегөлсем Болгарская -** татар сәхнәсенең күренекле остасы. Иҗатын “Сәйяр” труппасында башлап җибәрә. Аңа берүк спектакльдә берничә рольне берьюлы башкарырга туры килә. Иҗатындагы төп темаларның берсе – хатын-кыз азатлыгы. |
| **Нәфис сүз остасы, артист – Мохтар Мутин (1886-1941)** (пенсне кигән, таза, нык гәүдәле, озын чәчле, өстендә кара бәрхет толстовка, муенында ак тасмадан бик зур бант) |  | **Мөхтәр Мутин** - татар халкының бөек трагик артисты, режиссер, тәрҗемәче, театр эшен оештыручы.<br>Аны “татар Отеллосы” дип йөртәләр.<br>Репрессия корбаны. 1941 елда Колымада үлә. Аның белән бергә төрмәдә булган язучы И.Сәлахов әйтүенчә төрмәчеләр аны этләрдән талатып үтерттерәләр.<br>1963 елда аклана. |

| | | |
|---|---|---|
| **Язучы, сатирик, журналист - Фатих Әмирхан (1886-1926)** |  | **Фатих Әмирхан** - күренекле татар язучысы, драматург, публицист, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе. Татар сатира жанрын тудыручы.<br>Фатих Әмирхан күп әсәрләрендә искелекне, сыйнфый тигезсезлекне тәнкыйтьли. Шулай ук татар хатын-кызлары хокукларын да яклап чыга («Татар кызы»).<br>Тукайның якын дусты була. Тукай вафатыннан соң бер ел язмыйча торуы билгеле. |
| **Җырчы, опера җырчысы, композитор - Мәрьям Рахманкулова (1901-1990)** |  | **Мәрьям Рахманкулова** – татар җырчысы, опера артисты, композитор, җәмәгать эшлеклесе. Фатиха Аитованың кызлар мәктәбендә укыган. Фатиха ханым Мәрьямне укыганда ук күреп, киләчәктә мәктәбенең мөгаллимәсе итәргә җыена, тик аның төрле кичәләрдә җырлавын әдәпсезлек дип саный. Шуңа күрә кызны мәктәптән читләштерә. Әнисе бик үтенеп сораганнан соң Мәрьямне кабат мәктәпкә ала, тик аның халык алдына чыгып җырлавын катгый тыя. Мәрьям соңыннан мәктәптән бөтенләй читләшә һәм гомерен музыкага багышлый. |
| **Музыкант, композитор - Салих Сәйдәшев (1900-1954)** |  | **Салих Сәйдәшев** – күренекле татар композиторы, татар профессиональ музыкасына нигез салучы. Танылган “Кызыл армия маршы”, “Сәйдәш вальсы” авторы. Ул татар сәнгате тарихында беренче мәртәбә яңа жанр - музыкаль драма жанрын башлап җибәрә. К.Тинчуринның “Зәңгәр шәл”, “Кандыр буе”, “Казан сөлгесе”, Т.Гыйззәтнең “Наемщик” һ.б. драмаларына көйләр яза. |

| **Габдулла Тукай** | **Сәгыйть Рәмиев “Таң вакыты”** |
|---|---|
| Халыкка дәрсе гыйбрәттер — театр,<br>Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.<br>Театр — яктылыкка, нурга илтә,<br>Кире юлга җибәрми, уңга илтә. | Таң вакыты... Татар йоклый...<br>Мин йокысыз, уянам,<br>Уянам да, тиле кебек,<br>Тик берүзем уйланам. |

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.
Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең —
Көләрлек булса, булмаса — еларсың.
Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә — император.
Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,
Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул.

Уйланам, уема батамын,
Тормыймын үзем, ятам...
Ятмас идем дә, җибәрми
Атадан калган хатам.
Уйлан, татар, ту яңадан,
Мәгърифәтле анадан.
Бул кеше, үзең тырыш,
Юкса, бетәрсең, надан!

...Бетмә татар, ту яңадан
Мәгърифәтле анадан!